**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ГЛАВА**
**СТЕПНООЗЕРСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО**
**РАЙОНА**
423009, с. Степное Озеро, ул. Школьная, дом 23, телефон:8(84345) 4-63-34

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ**
**РАЙОНЫ**
**БИ КҮЛЕ**
**АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ**
**БАШЛЫГЫ**

423009, Бикүле авылы, Мәктәп ур., 23 йорт, телефон:8(84345) 4-63-34

ОГРН 1021605352438,ОКПО 04312541, ОКАТО 92246880000,
ИНН/ КПП 1632001635/163201001,ОКТМО 92646480

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**« 17 » октябрь 2025 ел** **№ 2**

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Би Күле авыл җирлегенең Би Күле авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын уздыруны билгеләү турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Би Күле авыл җирлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Нурлат муниципаль районының Би Күле авыл җирлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2025 елның 29 октябрендә 09 сәгать 00 минутта Мәктәп урамы буенча 19нчы йорт янында Нурлат муниципаль районы Би Күле авыл җирлегенең Би Күле авылындаТукай, Мәктәп урамы, Дружба урамы, Ленин урамы буенча, М. Җәлил урамы буенча 23-51, № 52-62 йортларда яшәүче гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының беренче этабын уздыруны билгеләргә.

2. 2025 елның 29 октябрендә 10 сәгать 00 Ш. Камал урамы, 2нче йорт янында Нурлат муниципаль районы Би Күле авыл җирлегенең Би Күле авылында Гагарин ур., Ш. Камал ур., Шоссе, Зеленая урамында яшәүче гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының икенче этабын уздыруны билгеләргә.

3. 2025 елның 29 октябрендә 11 сәгать 00 минутта М.Җәлил урамы буенча 21нче йорт янында Нурлат муниципаль районы Би Күле авылында М. Җәлил урамы буенча 1-21, 2-50 нче йортларда, Тихая, Һ. Такташ урамында яшәүче гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының өченче этабын билгеләргә.

4. Би Күле авылында яшәүчеләр исемлеген гражданнар җыенын уздыру өчен сайлау тәртибен территориаль билге буенча башкарырга.

5. Гражданнар җыены этапларын үткәрү һәм оештыру эше Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Би Күле авыл җирлеге башлыгы һәм Башкарма комитеты тарафыннан башкарыла

6. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Би Күле авыл җирлегенең Би Күле авылында яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, балачак инвалидларыннан, 1 гр инвалидлардан тыш, 2026 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- торак пункт территориясен төзекләндерү;

«РИЗА» «КАРШЫ»

8. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (игълан итәргә) һәм Нурлат муниципаль районының рәсми сайтына http://nurlat.tatarstan.ru урнаштырырга, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Би Күле авылының мәгълүмат стендларында халык җыены этапларын үткәрү датасына кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча хәбәр итәргә.

9. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Би Күле авыл җирлеге башлыгы А.М. Шакирова